ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 8 өлешендә “дәүләт хезмәтенең әйдәүче вазыйфаларын” сүзләрен “дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең барлык категорияләре һәм дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменең “җитәкчеләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын” сүзләренә алмаштырырга;

2) 35 статьяның 2 өлешендә “максатчан кабул итү турында шартнамә яисә” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 41 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктында “максатчан кабул итү турында шартнамәләр һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көчләренә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 06 октябрь
№ 63-ТРЗ